РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

10.11.2020 **г.Чистополь** № 231

Чистай шәһәрендә социаль наем
шартнамәләре буенча бирелә торган
торак урыннарына мохтаҗ аерым
категориядәге гражданнарны исәпкә кую буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын
яңа редакциядә раслау турында

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында"гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында"гы 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары нигезендә, Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ аерым категориядәге гражданнарны яңа редакциядә исәпкә кую муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. “Торак урыннарына мохтаҗ аерым категориядәге гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 2019 елның 25 декабрендәге 253 номерлы Чистай шәһәр Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садиковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов